Татарстан Республикасы

АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

«УРМАНДӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

№ 3

24.10.2022 ел

« Татарстван Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең Савгач торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Урмандәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең Савгач авылында яшәүче гражданнар өчен 2022 елның 03 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләгә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

   «2023 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең Савгач авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан өлешчә мобилизация буенча мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары, тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән, Сез килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

1) таш сатып алу, Савгач авылы т. п. (сатып алу, ташу,)

2) юлларны кышкы карап тоту (килешү буенча эшләр өчен түләү)

2) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу:

1) контейнерлар сатып алу

3)территорияне төзекләндерү:

Халык күпләп ял итә алсын өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру:

- балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын тоту

- Савгач авылында зират коймасы (төзелеш материаллары сатып алу,килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыеннарын оештыру һәм үткәрү өчен Урмандәй авыл җирлеге башкарма комитетына җаваплылык йөкләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Урмандәй авыл җирлеге башлыгы: В.З.Николаев